ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2020 елның 18 мартыннан №21

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2006 елның 2 маеннан 59-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында», 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында», Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында: www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә.

Бәзәкә авыл җирлеге
Башлыгы И.И.Кәшәфетдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкәавылҗирлеге
Башкармакомитетының
2020 елның 18 мартыннан
21нче номерлы карарына

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципальрайонының Бәзәкәавылҗирлегебашкармакомитетынагражданнардан кергәнмөрәҗәгатьләргә анализ ясаутәртибе

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 23 статьясынүтәүөченэшләнгән«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитеты награжданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданна мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай УК гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3.Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, электрон документ формасында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү юлы белән, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итүбарышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

5.Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча хисап чорыннансоңкилэторганайның 10 числосынакадәр аналитик белешмәтөзелә.

6. Аналитик белешмәдәгражданнарнышәхси кабул итүдә кабул ителгәнгражданнарның саны, гражданнар шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турындагы мәгълүмат (булган очракта) булырга тиеш.

7.Җирле үз идарә органына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда алдагы елның шушы чорына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Аналитик белешмә ел саен Менделеевск муниципальрайонының рәсмисайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә хисап чорыннан соң килә торганайның 15 числосына кадәр урнаштырыла.